ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 29 » октября 2019 ел № 822

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында финанс-бюджет өлкәсендә тикшереп тору вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Тәртипләрен раслау турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 269.2 статьясына, «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 99 статьясына таянып, Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР бирә:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының эчке муниципаль финанс тикшереп торуы органы тарафыннан «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның үтәлешен тикшереп тору Тәртибен 1 нче Кушымта нигезендә расларга.

2. Эчке муниципаль финанс тикшереп торуы органы тарафыннан финанс-бюджет өлкәсендә тикшереп тору вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Тәртибен 2 нче Кушымта нигезендә расларга.

3. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 20 декабрендәге 1247 номерлы “Арча муниципаль районының муниципаль финанс тикшереп торуы органы тарафыннан «Дәүләт һәм

муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында” 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның үтәлешен тикшереп тору тәртибе хакында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге тәртипне Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар Рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм “Интернет” челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р.Мөхәрәмовка йөкләргә.

Җитәкче И.Ә. Галимуллин

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
башкарма комитетының
2019 елның “29” октябрь
822 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының эчке муниципаль финанс тикшереп торуы органы тарафыннан «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның үтәлешен тикшереп тору Тәртибе**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге тәртип Арча муниципаль районының эчке муниципаль финанс тикшереп торуы органы - “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы финанс-бюджет палатасы” МКУ тарафыннан «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның үтәлешен тикшереп тору тәртибен билгели (алга таба-Тәртип, Тикшереп тору органы, Федераль закон).

2. Федераль законның үтәлешен тикшереп тору буенча Тикшереп тору органы эшчәнлеге (алга таба – тикшереп тору эшчәнлеге) законлылык, дөреслек, нәтиҗәлелек, бәйсезлек, һөнәри компетентлык, нәтиҗәләр дөреслеге һәм хәбәрдарлык принципларына нигезләнергә тиеш.

3. Тикшереп тору эшчәнлеге планлы һәм планнан тыш тикшерүләр (алга таба - контроль чаралар) үткәрү юлы белән башкарыла. Тикшерүләр күчмә һәм камераль тикшерүләргә, шулай ук күчмә һәм (яки) камераль тикшерүләр кысаларында үткәрелә торган каршы тикшерүләргә бүленә.

4. Тикшереп тору органнарының тикшереп тору эшчәнлеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлары булып түбәндәгеләр тора:

а) Тикшереп тору органы җитәкчесе;

б) Тикшереп тору органы җитәкчесенең вазыйфасына тикшерү эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләре кергән урынбасары;

в) Тикшереп тору органының контроль чараларын гамәлгә ашыруны оештыру өчен җаваплы бүлекләре башлыгы;

г) Тикшереп тору органы җитәкчесенең (җитәкче урынбасары) күрсәтмәсе нигезендә Тикшереп тору органының контроль чаралар үткәрүдә катнашырга вәкаләтле башка муниципаль хезмәткәрләре.

5. Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән вазыйфаи затларның бурычлары:

а) Тикшереп тору органнары эшчәнлеге өлкәсендә билгеләнгән норматив хокукый актларның таләпләрен үтәргә;

б) Тикшереп тору органы җитәкчесе (җитәкчесе урынбасары) боерыгы нигезендә контроль чаралар үткәрергә;

в) тикшерү субъекты җитәкчесен яки вәкаләтле вазыйфаи затын – муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алуга юнәлдерелгән гамәлләр башкаручы заказчылар, контракт хезмәтләре, контракт идарәчеләре, вәкаләтле органнар, вәкаләтле учреждениеләрне - Тикшереп тору органы җитәкчесенең (урынбасарының) контроль чара билгеләү, күчмә һәм камераль тикшерүләрне туктатып тору, яңарту, срокларын озайту, Тикшереп тору органының тикшерү төркеме составын үзгәртү турында боерык күчермәсе белән, шулай ук күчмә һәм камераль тикшерүләрнең нәтиҗәләре белән таныштырырга;

г) җинаять составы билгеләре булган гамәлләр кылу (гамәл кылмау) факты ачыкланганда, мондый фактны ачыклау датасыннан соң 3 эш көне эчендә әлеге фактны раслаучы мәгълүмат һәм (яки) документларны, башка материалларны Тикшереп тору органы җитәкчесе (җитәкче урынбасары) карары белән хокук саклау органнарына җибәрергә;

д) башка дәүләт (муниципаль) органнар (вазыйфаи зат) компетенциясенә караган хокук бозу билгеләрен раслаучы хәлләр һәм фактлар ачыкланганда, Тикшереп тору органы җитәкчесе (җитәкче урынбасары) карары белән мондый фактлар һәм хәлләр ачыклану датасыннан соң 10 эш көне эчендә тиешле органга (вазыйфаи затка) мәгълүмат җибәрергә.

6. Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән вазыйфаи затлар Федераль законның 99 статьясындагы 27 өлеше нигезендә түбәндәгеләргә хокуклы:

а) контроль чаралар үткәрү өчен кирәкле документлар һәм мәгълүматны соратырга һәм аңлатылган сорату нигезендә язма формада алырга;

б) контроль чараларны гамәлгә ашырганда Тикшереп тору органы җитәкчесенең (җитәкче урынбасары) контроль чара билгеләү турында боерыгы күчермәсе һәм һәм хезмәт таныклыгын күрсәтеп, контроль субъектлары биналарына һәм территорияләренә тоткарлыксыз керергә, алынган товарлар күрсәтүне, башкарылган эшләр, күрсәтелгән хезмәтләрнең нәтиҗәләрен таләп итәргә, шулай ук кирәкле сынаулар һәм контрольлек итү буенча башка чаралар үткәрергә;

в) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән очракларда, ачыкланган дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарын һәм башка норматив хокукый актларны бозуларны бетерү турында үтәү мәҗбүри булган күрсәтмәләр бирергә;

г) сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарын һәм башка норматив хокукый актларны бозулар белән бәйле административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә, Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә мондый административ хокук бозулар турында эшләрне карарга, һәм аларны булдырмау буенча чаралар күрергә;

д) Россия Федерациясе Гражданлык кодексы нигезендә сатып алуларны дөрес түгел дип тану турында судка, Арбитраж судына дәгъвалар белән мөрәҗәгать итәргә.

7. Тикшереп тору органының вазыйфаи затлары тарафыннан контроль чаралар кысаларында төзелә торган барлык документлар контроль чара материалларына теркәлә, исәпкә алына һәм саклана, шул исәптән автоматлаштырылган системада да.

8. Документлар һәм мәгълүмат бирү турында соратулар, тикшерү актлары, күрсәтмәләр контрольлек субъектларының җитәкчеләренә яисә вәкаләтле вазыйфаи затларына (алга таба - контроль субъекты вәкиле) тапшырыла яисә тапшыру турында хәбәрнамә белән, яки адресат тарафыннан алу датасын таныклаган, шул исәптән автоматлаштырылган мәгълүмат системаларын кулланып та, заказлы хат белән почта аша җибәрелә.

9. Контроль субъекты тарафыннан документлар һәм мәгълүмат тапшыру вакыты соратуда билгеләнә һәм контроль субъекты тарафыннан сорату алу датасыннан исәпләнә.

10. Бердәм мәгълүмат системасында урнаштыру өчен мәҗбүри документлар булып сатып алулар өлкәсендә күчмә яки камераль тикшерү нәтиҗәләре турында Тәртипнең 42 пункты нигезендә төзелгән хисап, Тәртипнең 42 пунктындагы "а" пунктчасы нигезендә контроль субъектына бирелгән күрсәтмә тора.

11. Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән вазыйфаи затлар, Россия Федерациясе законнары нигезендә, тикшерү чараларын гамәлгә ашыру барышында кылган гамәлләр һәм карарлар (гамәл кылмаулар) өчен җаваплы.

12. Контроль чараны гамәлгә ашыру процедураларына контроль чара билгеләү, контроль чара үткәрү һәм контроль чара үткәрү нәтиҗәләрен тормышка ашыру керә.

## II. Контроль чараларны билгеләү

13. Контроль чара Тикшереп тору органы җитәкчесе (җитәкче урынбасары) тарафыннан контроль чараны билгеләү турында күрсәтмә нигезендә тикшереп тору органының вазыйфаи заты (вазыйфаи затлары) тарафыннан үткәрелә.

14. Контроль чара билгеләү турында Тикшереп тору органы җитәкчесе (җитәкче урынбасары) күрсәтмәсендә түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

а) тикшерү субъектының исеме;

б) тикшерү субъектының урнашу урыны;

в) тикшерү субъекты эшчәнлеген фактта гамәлгә ашыру урыны;

г) тикшерү вакыты;

д) контроль чара үткәрүнең нигезе;

е) контроль чараның темасы;

ж) Тикшереп тору органы вазыйфаи затының (бер вазыйфаи зат тарафыннан камераль тикшерү уздырганда), тикшерү чарасын үткәрүгә вәкаләтле Тикшереп тору органының тикшерү төркеме әгъзалары, тикшерү төркеме җитәкчесе, (контроль чара тикшерү төркеме тарафыннан үткәрелгәндә), шулай ук тикшерү үткәрүгә җәлеп ителгән эксперт оешмалары вәкилләре, экспертларның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы-булган очракта);

з) контроль чараны үткәрү вакыты;

и) контроль чара уздыру барышында өйрәнелергә тиешле төп мәсьәләләр исемлеге.

15.Тикшереп тору органының тикшерү төркеменең вазыйфаи затлары составын үзгәртү, шулай ук контроль чара үткәрүгә вәкаләтле Тикшереп тору органының вазыйфаи затын алыштыру (бер вазыйфаи зат тарафыннан камераль тикшерү уздырганда) Тикшереп тору органы җитәкчесе (җитәкче урынбасары) боерыгы белән рәсмиләштерелә.

16. Планлы тикшерүләр Тикшереп тору органы тарафыннан расланган план нигезендә гамәлгә ашырыла.

17. Контрольнең бер субъектына карата планлы тикшерүләр үткәрү ешлыгы елына 1 тапкырдан да артмаска тиеш.

18. Планнан тыш тикшерүләр Тикшереп тору органы җитәкчесе (җитәкче урынбасары) кабул иткән карар нигезендә үткәрелә:

а) Россия Федерациясенең дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында законы һәм аның нигезендә кабул ителгән норматив хокукый (хокукый) актларны бозу турында кергән мәгълүмат нигезендә;

б) элек бирелгән күрсәтмәнең үтәлү вакыты чыкканда;

в) Гомуми таләпләрнең 42 пунктындагы "в" пунктчасында каралган очракта.

## III. Контроль чараларны үткәрү

19. Камераль тикшерү бер вазыйфаи зат яки тикшерү төркеме тарафыннан үткәрелергә мөмкин.

20. Күчмә тикшерү Тикшереп тору органының кимендә ике вазифаи затыннан торган тикшерү төркеме тарафыннан үткәрелә.

21. Тикшереп тору органының тикшерү төркеме җитәкчесе итеп административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле Тикшереп тору органының вазыйфаи заты билгеләнә.

Камераль тикшерү Тикшереп тору органының бер вазыйфаи заты тарафыннан үткәрелсә, әлеге вазыйфаи зат административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле булырга тиеш.

22. Камераль тикшерү Тикшереп тору органы урнашкан урында контрольлек субъекты тарафыннан тапшырылган документлар һәм мәгълүмат, шулай ук сатып алулар өлкәсендә мәгълүмат бердәм мәгълүмат системасы анализы нәтиҗәсендә алынган документлар һәм мәгълүматлар нигезендә уздырыла.

23. Камераль тикшерүне үткәрү вакыты Тикшереп тору органы соратуы буенча контроль субъектыннан мәгълүмат һәм документлар алынганнан соң 20 эш көненнән дә артмаска тиеш.

24. Тикшереп тору органы вазыйфаи заты тарафыннан камераль тикшерү уздырганда (бер вазыйфаи зат тарафыннан камераль тикшерү уздырганда) яисә Тикшереп тору органының тикшерү төркеме тарафыннан тикшерү уздырганда, Тикшереп тору органы тарафыннан контроль субъектыннан соратып алынган документлар һәм мәгълүматның тулылыгын тикшерү әлеге документлар һәм мәгълүматны контроль субъектыннан алган көннән соң 3 эш көне эчендә үткәрелә.

25. Тәртипнең 24 пункты нигезендә, контроль субъекты тапшырган документлар һәм мәгълүматның тулылыгын тикшерү нәтиҗәләре буенча соратылган контроль субъекты тарафыннан тапшырылган документлар һәм мәгълүматның тулы түгеллеге ачыкланса, документлар һәм мәгълүматның тулылыгын тикшерү тәмамланганнан соң, Тәртипнең 32 пунктындагы "г" пунктчасы нигезендә, камераль тикшерү үткәрү туктатып торыла.

Бер үк вакытта, Тәртипнең 34 пункты нигезендә, контроль субъекты адресына камераль тикшерүне туктатып тору турындагы карарның күчермәләрен җибәрү белән бергә, тикшерү үткәрү өчен кирәкле җитмәгән документлар һәм мәгълүмат тапшыру турында сорату кабат җибәрелә.

Тикшереп тору органы тарафыннан кабат соратылган документлар һәм мәгълүмат контроль субъекты тарафыннан тикшерүне туктатып тору вакыты чыкканчы

тапшырылмаган очракта, Тәртипнең 32 пунктындагы "г" пункты нигезендә тикшерү яңадан торгызыла.

Контроль субъекты тарафыннан документлар һәм мәгълүмат тапшырмау факты тикшерү нәтиҗәләре буенча рәсмиләштерелә торган актта теркәлә.

26. Күчмә тикшерү контроль субъекты эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны һәм урнашу урыны буенча үткәрелә.

27. Күчмә тикшерүне үткәрү вакыты 30 эш көненнән дә артмаска тиеш.

28. Күчмә тикшерү барышында контроль субъекты эшчәнлеген документаль һәм фактта өйрәнү буенча тикшерү эшләре алып барыла.

Документларны өйрәнү буенча контроль гамәлләр, контроль субъектының телдән һәм язма аңлатмаларын исәпкә алып, контроль субъектының финанс, бухгалтерия, хисап документларын, планлаштыру һәм сатып алуларны башкару һәм башка документларын анализлау юлы белән үткәрелә.

Фактта өйрәнү буенча контроль гамәлләр тикшерү, инвентаризация үткәрү, күзәтү, яңадан исәпләү, сынаулар, контроль үлчәүләр һәм башка гамәлләрне тормышка ашыру юлы белән башкарыла.

29. Күчмә яки камераль тикшерүне үткәрү вакыты Тикшереп тору органы җитәкчесе ((җитәкче урынбасары) карары буенча 10 эш көненә кадәр озайтылырга мөмкин.

Тикшереп тору органы вазыйфаи затының (бер вазыйфаи зат тарафыннан камераль тикшерү уздырганда) яки Тикшереп тору органының тикшерү төркеме җитәкчесенең дәлилләнгән мөрәҗәгате нигезендә контроль чара срогын озайту турындагы карар кабул ителә.

Контроль чараның вакытын озайтуга нигез булып, тикшерү барышында контроль субъекты эшчәнлегендә өстәмә өйрәнүне таләп итә торган дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарын, шул нигездә кабул ителгән норматив хокукый (хокукый) актларны бозулар турында мәгълүмат алу тора.

30. Күчмә яки камераль тикшерү кысаларында каршы тикшерү Тикшереп тору органы җитәкчесе (җитәкче урынбасары) карары буенча Тикшереп тору органы вазыйфаи затының (бер вазыйфаи зат тарафыннан камераль тикшерү уздырганда) яки Тикшереп тору органының тикшерү төркеме җитәкчесенең дәлилләнгән мөрәҗәгате нигезендә үткәрелә.

Каршы тикшерү барышында дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарын бозу фактларын билгеләү һәм (яки) раслау яисә юкка чыгару максатында, контроль гамәлләр үткәрелә.

31. Каршы тикшерү Тәртипнең 19 - 22, 26, 28 нче пунктларында билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.

Каршы тикшерүне үткәрү вакыты 20 эш көненнән дә артмаска тиеш.

32. Тикшереп тору органы җитәкчесе (җитәкче урынбасары) карары буенча Тикшереп тору органы вазыйфаи затының (бер вазыйфаи зат тарафыннан камераль тикшерү уздырганда) яки Тикшереп тору органының тикшерү төркеме җитәкчесенең дәлилләнгән мөрәҗәгате нигезендә күчмә яисә камераль тикшерү 30 эш көненнән дә артмаган гомуми срокка түбәндәге очракларда туктатып торыла:

а) 20 эш көненнән артмаган каршы тикшерү үткәрү чорына;

б) 20 эш көненнән артмаган экспертизалар оештыру һәм үткәрү чорына;

в) 20 эш көненнән артмаган контроль чараны үткәрүгә комачаулау чорына һәм (яки) контроль чараны үткәрүдән читләшүләр чорына;

г) Гомуми таләпләрнең 25 пункт нигезендә, контроль субъектыннан Тикшереп тору органы тарафыннан кабат сорату буенча документлар тапшыру өчен кирәкле 10 эш көненнән артмаган чорга;

д) 20 эш көненнән артмаган вакыт аралыгында, Тикшереп тору органы вазыйфаи затының (бер вазыйфаи зат тарафыннан камераль тикшерү уздырганда) яки тикшерү төркеменә бәйсез сәбәпләр аркасында контроль чараны алга таба үткәрү мөмкин булмаган очракта, шул исәптән җиңеп булмаслык шартлар туганда.

33. Күчмә яки камераль тикшерүне үткәрүне яңарту турында карар 2 эш көненнән дә артык булмаган вакыт эчендә түбәндәге очракларда кабул ителә:

а) Тәртипнең 32 пунктының "а", "б" пунктчалары нигезендә, каршы тикшерү һәм (яки) экспертиза үткәрү беткәннән соң;

б) Тәртипнең 32 пунктындагы "в" - "д" пунктчаларында күрсәтелгән тикшерүне үткәрүне туктатып тору сәбәпләрен бетергәннән соң;

в) Тәртипнең 32 пунктындагы "в" - "д" пунктчаларында күрсәтелгән тикшерүне туктатып тору вакыты чыкканнан соң.

34. Күчмә яки камераль тикшерү үткәрү вакытын озайту, туктатып тору, яңарту турында карар, тикшерү үткәрү вакытын озайту, туктатып тору, яңартуны нигезләп, Тикшереп тору органы җитәкчесе (җитәкче урынбасары) күрсәтмәсе белән рәсмиләштерелә.

Күчмә яки камераль тикшерү үткәрү вакытын озайту, туктатып тору, яңарту турында Тикшереп тору органы җитәкчесе (җитәкче урынбасары) карарының күчермәсе, тиешле боеру документы чыккан көннән алып 3 эш көненнән дә артмаган вакыт эчендә, тикшерү субъектына җибәрелә (тапшырыла).

35. Тәртипнең 6 пунктындагы “а” пунктчасы нигезендә, Тикшереп тору органы соратуы буенча тапшырылмаган яки вакытында тапшырылмаган документлар һәм мәгълүмат яки белә торып дөрес булмаган документлар тапшырганда, Тикшереп тору органы тарафыннан Россия Федерациясенең административ хокук бозулар турында законнары белән билгеләнгән җаваплылык чаралары кулланыла.

## IV. Контроль чараларның нәтиҗәләрен рәсмиләштерү

36. Каршы тикшерү нәтиҗәләре Тикшереп тору органы вазыйфаи заты имзалаган (бер вазыйфаи зат тарафыннан камераль тикшерү уздырганда), яисә тикшерү төркеменең барлык әгъзалары имзалаган (тикшерү төркеме тарафыннан тикшерү уздырганда) акт белән тикшерү үткәрүнең соңгы көнендә рәсмиләштерелә һәм күчмә яки камераль тикшерү материалларына теркәлә.

Каршы тикшерү нәтиҗәләре буенча контроль субъектына күрсәтмәләр бирелми.

37. Күчмә яки камераль тикшерү нәтиҗәләре Тикшереп тору органы вазыйфаи заты имзалаган (бер вазыйфаи зат тарафыннан камераль тикшерү уздырганда), яисә тикшерү төркеменең барлык әгъзалары имзалаган (тикшерү төркеме тарафыннан тикшерү уздырганда) акт белән тикшерү чарасы беткән көннән соң 3 эш көненнән артмаган вакыт эчендә рәсмиләштерелә.

38. Күчмә яки камераль тикшерү нәтиҗәләре буенча рәсмиләштерелгән актка экспертиза нәтиҗәләре, фото -, видео - һәм аудиоматериаллар, каршы тикшерү акты (ул уздырылган очракта), шулай ук контроль чаралар барышында алынган башка материаллар

теркәлә.

39. Күчмә яки камераль тикшерү нәтиҗәләре буенча рәсмиләштерелгән акт, кул куелганнан соң 3 эш көненнән дә артмаган вакыт эчендә, контроль субъекты вәкиленә тапшырылырга (җибәрелергә) тиеш.

40. Контроль субъекты, актны алган көннән соң 10 эш көне эчендә, күчмә яки камераль тикшерү нәтиҗәләре буенча рәсмиләштерелгән актка язма каршылыклар тапшырырга хокуклы,

Контроль субъектының язма каршылыклары тикшерү материалларына теркәлә.

41. Күчмә яки камераль тикшерү нәтиҗәләре буенча рәсмиләштерелгән акт, контроль субъекты каршылыклары (булган очракта) һәм күчмә яки камераль тикшерүнең башка материаллары Тикшереп тору органы җитәкчесе (җитәкче урынбасары) тарафыннан каралырга тиеш.

42. Күчмә яки камераль тикшерү нәтиҗәләре буенча рәсмиләштерелгән актны, контроль субъекты каршылыкларын исәпкә алып (булган очракта), карау һәм күчмә яки камераль тикшерүнең башка материалларын карау буенча Тикшереп тору органы җитәкчесе (җитәкче урынбасары), актка кул куелганнан соң 30 эш көненнән артмаган вакыт эчендә, түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) Федераль закон белән билгеләнгән очракларда, үтәү өчен мәҗбүри күрсәтмәне бирү турында;

б) күрсәтмә бирү өчен нигезләрнең булмавы турында;

в) планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында.

Тикшереп тору органы җитәкчесе (җитәкче урынбасары) тарафыннан югарыда күрсәтелгән боерыкка кул кую белән бер үк вакытта, Тикшереп тору органы җитәкчесе (җитәкче урынбасары) тарафыннан тикшерү уздырганда ачыкланган барлык бозулар һәм контроль субъекты каршылыкларын караганнан соң расланган (булган очракта) бозулар кертелгән күчмә яки камераль тикшерү нәтиҗәләре турында хисап раслана.

Күчмә яки камераль тикшерү нәтиҗәләре турындагы хисапка контроль органының вазыйфаи заты (бер вазыйфаи зат тарафыннан камераль тикшерү уздырганда) яки тикшерү үткәргән Тикшереп тору органының тикшерү төркеме җитәкчесе кул куя.

Күчмә яки камераль тикшерү нәтиҗәләре турында хисап тикшерү материалларына теркәлә.

## V. Контроль чаралар нәтиҗәләрен тормышка ашыру

43. Күрсәтмә, Тәртипнең 42 пунктындагы "а" пунктчасы нигезендә, үтәү өчен мәҗбүри булган күрсәтмәне бирү турында карар кабул ителгән көннән алып 5 эш көненнән дә артмаган вакыт эчендә, контроль субъекты вәкиленә җибәрелә (тапшырыла).

44. Күрсәтмәдә аны үтәү сроклары булырга тиеш.

45. Тикшереп тору органының вазыйфаи заты (бер вазыйфаи зат тарафыннан камераль тикшерү уздырганда) яисә Тикшереп тору органының тикшерү төркеме җитәкчесе контроль субъекты тарафыннан күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торырга тиеш.

Билгеләнгән вакытта Тикшереп тору органы күрсәтмәсен үтәмәгән затка Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылык чаралары кулланыла.

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
башкарма комитетының
2019 елның “29” октябрь
822 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында эчке муниципаль финанс тикшереп торуы органы тарафыннан финанс-бюджет өлкәсендә тикшереп тору вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Тәртибе**

**I. Гомуми нигезләмәләр**

1. Әлеге Тәртип, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 269.2 статьясындагы 3 өлешен үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Финанс-бюджет палатасы” муниципаль казна учреждениесенең (алга таба Палата) финанс-бюджет өлкәсендә тикшереп тору вәкаләтләрен гамәлгә ашыруын билгели.

2. Тикшереп тору эшчәнлеге законлылык, дөреслек, нәтиҗәлелек, бәйсезлек, һөнәри компетентлык, нәтиҗәләрнең дөреслеге һәм хәбәрдарлык принципларына нигезләнә.

3. Тикшереп тору эшчәнлеге планлы һәм планнан тыш тикшерүләргә бүленә һәм планлы һәм планнан тыш тикшерүләр үткәрү, шулай ук финанс-бюджет өлкәсендә планлы һәм планнан тыш тикшерүләр һәм ревизияләр (алга таба - контроль чаралар) эчке муниципаль финанс контроле вәкаләтләре кысаларында гына гамәлгә ашырыла. Тикшерүләр күчмә һәм камераль тикшерүләргә, шулай ук күчмә һәм (яки) камераль тикшерүләр кысаларында үткәрелә торган каршы тикшерүләргә бүленә.

4. Планлы контроль чаралар Арча муниципаль районы Башлыгы һәм Башкарма комитет җитәкчесе белән килештерелеп, планлаштырылган елга кадәрге елның 25 декабреннән дә соңга калмыйча Палата җитәкчесе (алга таба – Җитәкче) тарафыннан расланган контроль чаралар планы нигезендә гамәлгә ашырыла.

5. Планнан тыш контроль чаралар Палата җитәкчесе кабул иткән карар нигезендә түбәндәге очракларда гамәлгә ашырыла:

Татарстан Республикасы Президенты, муниципаль район Башлыгы, Арча муниципаль район Советы, муниципаль район Башкарма комитеты, хокук саклау органнары, башка дәүләт һәм муниципаль органнар мөрәҗәгатьләре (йөкләмәләре), депутат соратулары, гражданнар һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләре кергән очракта;

Палатаның вазыйфаи заты вазыйфаи бурычларын үтәү барышында Палатаның эшчәнлеге өлкәсенә кагылышлы мәсьәләләр буенча, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларыннан, закон һәм башка норматив хокукый актларны бозу турында мәгълүмат алган очракта;

элегрәк бирелгән күрсәтмәнең үтәлү вакыты чыккан очракта;

әлеге Тәртипнең 36 пунктында, 45 пунктның «в» пунктчасында һәм 63 пунктның «в» пунктчасында каралган очракларда.

6. Эчке муниципаль финанс тикшереп торуын гамәлгә ашыру буенча эчке муниципаль финанс тикшереп торуы органы вәкаләтләре булып түбәндәгеләр тора:

а) бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган хокукый актлар нигезләмәләренең, шул исәптән бухгалтерлык исәбенә һәм муниципаль учреждениеләрнең бухгалтерлык (финанс) хисабын төзү һәм тапшыруга таләпләрне билгели торган нигезләмәләрнең үтәлешен тикшереп тору;

б) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан физик затларга башка түләүләр буенча ачык норматив йөкләмәләрне билгели торган хокукый актлар нигезләмәләренең үтәлешен, шулай ук тиешле бюджеттан акча бирү турында шартнамәләр (килешүләр), муниципаль контрактлар шартларын үтәүне контрольдә тоту;

в) бюджеттан акча бирү турында шартнамәләрне (килешүләрне) үтәү максатларында төзелгән шартнамәләрнең (килешүләрнең) шартларын, шулай ук әлеге Нигезләмәдә каралган очракларда, муниципаль контрактларны үтәү максатларында төзелгән шартнамәләрнең (килешүләрнең) шартларын үтәүне тикшереп тору;

г) бюджет акчаларын (бюджеттан бирелгән акчалар) бирү һәм (яки) алардан файдалану нәтиҗәләре турындагы хисапларның, шул исәптән муниципаль программаларны тормышка ашыру турындагы хисапларның, муниципаль биремнәрнең үтәлеше турындагы хисапларның, бюджеттан акча бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турындагы хисапларның дөреслеген тикшереп тору.

7. Муниципаль финанс тикшерүе объектлары булып торалар:

а) бюджет акчаларын баш бүлүчеләр (бүлүчеләр, алучылар), тиешле бюджет керемнәренең баш администраторлары (администраторлары), тиешле бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары (администраторлары);

б) бюджетына бюджетара субсидияләр, субвенцияләр, максатчан билгеләнештәге башка бюджетара трансфертлар, бюджет кредитлары бирелгән ачык-хокукый берәмлекнең финанс органы, җирле администрация;

в) муниципаль учреждениеләр;

г) муниципаль унитар предприятиеләр;

д) устав (җыелма) капиталларында ачык-хокукый берәмлекләр катнашкан хуҗалык ширкәтләре һәм җәмгыятьләр, шулай ук устав (җыелма) капиталларында мондый ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең өлеше (кертеме) булган коммерция оешмалары;

е) юридик затлар (муниципаль учреждениеләр, муниципаль унитар предприятиеләр, хуҗалык ширкәтләре һәм җәмгыятьләр катнашындагы ачык-хокукый оешмалар, шулай ук устав (җыелма) капиталларында мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр өлеше (кертеме) булган коммерция оешмаларыннан тыш), шәхси эшмәкәрләр, физик затлар:

ж) район бюджетыннан акча һәм (яки) муниципаль контрактлар бирү турындагы шартнамәләр (килешүләр) нигезендә бюджеттан акча алучы юридик һәм физик затлар, муниципаль гарантияләр белән тәэмин ителгән кредитлар бирү турында килешүләр (шартнамәләр) нигезендә бюджеттан акча алучы шәхси эшмәкәрләр;

з) бюджеттан акча һәм (яисә) муниципаль контрактларны бирү турында шартнамәләрне (килешүләрне) үтәү максатларында төзелгән шартнамәләр буенча федераль законнар нигезендә муниципаль берәмлекнең финанс органында шәхси счетлар ачылган башкаручылар (тәэмин итүчеләр, подрядчылар);

и) район бюджетыннан акча бирү турында шартнамәләр (килешүләр) шартларын үтәү өлешендә бюджет акчалары белән аерым операцияләр башкаручы кредит оешмалары.

8. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен сатып алуларны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны контрольдә тоту эшчәнлеген гамәлгә ашырганда, бер контроль чарасы кысаларында, Россия Федерациясенең бюджет законнары һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы башка норматив хокукый актлар үтәлешен тикшереп тору буенча Палатаның вәкаләтләре, шулай ук Палатаның контракт системасы турында Федераль законның 99 статьясындагы 8 өлешендә каралган вәкаләтләре гамәлгә ашырылырга мөмкин.

